215

# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**«Дәүләт милке һәм җирле үзидарә милке турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

**1 статья.** «Дәүләт милке һәм җирле үзидарә милке турында» 1999 елның 15 сентябрендәге 2353 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1999, № 10) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 4 статьяда:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Гражданнарның, юридик затларның йә территориясендә җирле үзидарә гамәлгә ашырыла торган төзелмәләрнең милкендә булмаган җир һәм башка табигый ресурслар дәүләт милке була.»;

3 пунктта «Әлеге статьяның 2 өлешендә күрсәтелгән» сүзләрен «Татарстан Республикасы милкендәге» сүзләренә алыштырырга.

2. 5 статьяда:

1 пунктта «(Татарстан Республикасы мөлкәте)» сүзләрен «(республика милке)» сүзләренә алыштырырга;

2 пунктны төшереп калдырырга;

3 пунктта «һәм коммуналь» сүзләрен төшереп калдырырга;

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Мөлкәт мөнәсәбәтләре буенча республика органы республика милке объектлары реестрын алып бара.

Әлеге реестрны алып бару тәртибе һәм аның эчтәлегенә таләпләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.».

3. 6 статьяның 5 пунктындагы беренче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы республика милке мөнәсәбәтләрен җайга салу өлкәсендәге Татарстан Республикасы

226

Конституциясендә, әлеге Законда һәм башка законнарда каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.».

4. 8-10 статьяларны төшереп калдырырга.

5. 11 статьяда:
исемендә «һәм коммуналь» сүзләрен төшереп калдырырга;
1 пунктта «яки җирле», «яисә җирле бюджетлардан», «яки коммуналь» сүзләрен төшереп калдырырга;
2 пунктта «яисә җирле», «яисә коммуналь» сүзләрен төшереп калдырырга;
3 пунктта «һәм 8 статьясындагы 5 нче өлешендә», «тиешле», «һәм коммуналь» сүзләрен төшереп калдырырга;
4 пунктта «яки коммуналь» сүзләрен төшереп калдырырга;
5 пунктта «яки коммуналь» сүзләрен төшереп калдырырга.

6. 12 статьяда:
исемендә һәм текстта «һәм коммуналь» сүзләрен төшереп калдырырга;
«Татарстан Республикасы» сүзләрен төшереп калдырырга.

7. 13 статья текстын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Шәһәрләр һәм авыллар, шулай ук территорияләрендә җирле үзидарә гамәлгә ашырыла торган башка төзелмәләр законнар белән тыелмаган теләсә кайсы эшчәнлек төрен башкару өчен файдаланыла торган мөлкәткә милекчелек хокукында ия булырга мөмкин. Бу мөлкәт, әгәр законда бүтәнчә билгеләнмәгән булса, теләсә кайсы юридик яисә физик затка вакытлыча яки даими файдалануга тапшырырлырга, физик, юридик затларның һәм милекчелек хокукына ия башка субъектларның мөлкәте белән берләштерелергә, залог предметы буларак файдаланылырга, юридик яисә физик затларга ышанычлы идарәгә тапшырылырга, читләштерелергә, файдаланылырга мөмкин һәм аңа башка йөкләүләр тапшырыла ала.».

8. 17 статьяда:
1 пунктта:
беренче абзацта «, коммуналь» сүзен төшереп калдырырга;
икенче абзацны төшереп калдырырга;
2 пунктның икенче абзацын төшереп калдырырга;
3 пунктта:
«коммуналь милеккә һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;
«дәүләт мөлкәте белән идарә итүче» сүзләрен «мөлкәт мөнәсәбәтләре буенча» сүзләренә алыштырырга;
4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«4. Республика милкендәге мөлкәтне җирле үзидарә милкенә тапшыру түләүсез башкарыла.»;

227

5 пунктта:
«коммуналь милеккә яки» сүзләрен төшереп калдырырга;
икенче абзацны төшереп калдырырга.

9. 18 статьяда:
исемендә «Коммуналь милеккә һәм җирле үзидарә милкенә» сүзләрен «Территорияләрендә җирле үзидарә гамәлгә ашырыла торган төзелмәләр милкенә» сүзләренә алыштырырга;
1 пунктта:
беренче абзацта «Коммуналь милеккә һәм җирле үзидарә милкенә» сүзләрен «Территорияләрендә җирле үзидарә гамәлгә ашырыла торган төзелмәләр милкенә» сүзләренә алыштырырга;
җиденче абзацта «дәүләт хакимияте һәм идарәсенең җирле органнарына һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;
2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2. Территориясендә җирле үзидарә гамәлгә ашырыла торган төзелмәләр милкенә тапшырыла торган республика милке объектлары составына бары тик дәүләт милкендә генә була ала торган мөлкәт кертелә алмый.».

10. 19 статьяда:
исемендә «Коммуналь милеккә һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;
1 пунктта «коммуналь милеккә һәм», «җирле администрацияләр яки» сүзләрен төшереп калдырырга;
2 пунктны түбәндәгечә бәян итәргә:
«2. Җирле үзидарә органы республика милкенең конкрет объектларын билгели, аларны җирле үзидарә милкенә тапшырырга тәкъдим итә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана торган рәвештә төзелүче исемлеккә кертә.»;
3 пунктта:
«җирле хакимият яки», «җирле хакимият яки» сүзләрен төшереп калдырырга;
«килештерә» сүзе татарча текстта үзгәрми;
«Килештерелгән исемлекләр» сүзләрен «Килештерелгән исемлек» сүзләренә алыштырырга;
«җибәрелә» сүзе татарча текстта үзгәрми;
«дәүләт мөлкәте белән идарә итүче» сүзләрен «мөлкәт мөнәсәбәтләре буенча» сүзләренә алыштырырга;
4 пунктта «Җирле хакимиятләр һәм» сүзләрен төшереп калдырырга.

11. 20 статьяда:
текстта «дәүләт мөлкәте белән идарә итүче» сүзләрен «мөлкәт мөнәсәбәтләре буенча» сүзләренә алыштырырга;

228

1 пунктта «коммуналь милеккә яки», «коммуналь төзелмә яки», «коммуналь милеккә яисә», «җирле администрация яисә» сүзләрен төшереп калдырырга;

2 пунктта «коммуналь милеккә яки», «дәүләт хакимияте һәм идарәсе органы һәм», «коммуналь төзелмәнең яки» сүзләрен төшереп калдырырга;

3 пунктта «коммуналь милеккә яисә», «коммуналь төзелмәнең яки» сүзләрен төшереп калдырырга;

4 пунктны төшереп калдырырга.

12. 21 статьяда:

«дәүләт мөлкәте белән идарә итү буенча» сүзләрен «мөлкәт мөнәсәбәтләре буенча» сүзләренә алыштырырга;

исемендә һәм 2 пунктта тиешле килешләрдәге «коммуналь милеккә һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

1, 3, 4 пунктларда тиешле килешләрдәге «коммуналь милек яки» сүзләрен төшереп калдырырга.

**2 статья.** Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — М.Ш.Шәймиев

Казан шәһәре,
2001 елның 21 ноябре

№ 1189